Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLI-4**

Балык Бистәсе штп.

2023 елның 28 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2023 елның 13 апрелендәге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» XXXVI-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Территорияне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге территориясендә җирдән тәртипле һәм нәтиҗәле файдалануны һәм төзелеш алып баруны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 маддәсенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2023 елның 13 апрелендәге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» XXXVI-2 номерлы карарына карарның 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пунктчасын өстәп үзгәрешләр кертергә (алга таба – карар):

«1.1 Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслауга бәйле рәвештә, реестр номерлары 16:34-7.5, 16:34-7.20, 16:34-7.21, 16:34-7.22, 16:34-7.23, 16:34-7.24, 16:34-7.25, 16:34-7.26, 16:34-7.27, 16:34-7.28, 16:34-7.29, 16:34-7.30, 16:34-7.31, 16:34-7.32, 16:34-7.33, 16:34-7.34, 16:34-7.35, 16:34-7.62, 16:34-7.63, 16:34-7.64, 16:34-7.65, 16:34-7.66, 16:34-7.67 булган гамәлдәге территориаль зоналарны дөрес түгел дип танырга һәм аларны «архив» статусына күчерергә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов